**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының мәгариф
идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә

ММҮ директорларына

Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында

**Хөрмәтле коллегалар!**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы 2013/2014 нче уку елында гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Татар теле» һәм «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәре буенча төзелгән үрнәк программалар турында һәм аларны куллану буенча түбәндәге аңлатманы җибәрә.

Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән гомуми белем бирүнең өч федераль дәүләт мәгариф стандарты (башлангыч гомуми белем бирү – № 373, 06.10.2009 ел; төп гомуми белем бирү – № 1897, 17.12.2010 ел; урта (тулы) гомуми белем бирү – № 413, 17.05.2012 ел) расланды.

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Татар теле», «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәрен укыту башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән базис һәм үрнәк уку-укыту планнары (Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 нче елның 9 нчы июлендә гамәлгә кертелгән 4154/12 санлы, 2012 нче елның 10 нчы июлендә гамәлгә кертелгән 4165/12 санлы боерыклары) һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 9777/12 нче санлы (13.08.2012 ел), 9127/13 нче санлы (09.07.2013 ел) хатлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары мәгариф системасына баскычлап кертелә. Башлангыч гомуми белем бирү баскычында федераль дәүләт белем стандарты 2011/2012 уку елыннан гамәлгә кертелде. Ә төп гомуми белем бирү баскычында яңа буын белем бирү стандартына күчү 2015/2016 уку елыннан, урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында - 2020/2021 уку елыннан тормышка ашырылачак.

Федераль дәүләт белем стандарты – алдагы елларга мәгариф үсеше стратегиясен билгеләүче норматив хокукый документ.

Үрнәк программа – фәннең уку-укыту планында тоткан урынын, аның үзләштерү өчен тиешле материалны үз эченә алган төп эчтәлеген, планлаштырыла торган нәтиҗәләрне ачыклаучы документ. Аның нигезендә авторлык программалары, укытучыларның эш программалары төзелә.

Башлангыч белем бирү баскычына татар теле һәм әдәби укудан өч төркем укучылар өчен (татар мәктәбендәге татар балалары, рус мәктәбендәге татар балалары һәм рус телле балалар төркемнәре) үрнәк программалар 2011 нче елда эшләнде һәм министрлыкның сайтына урнаштырылды: ***mon.tatarstan.ru/,*** *нормативные документы,/ внутренние документы министерства,/ приказы: стр.2, Приказ от 07.07.2011г. №3*


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

*утверждении программ (основного содержания) учебных предметов "Татарский язык" и "Литературное чтение на татарском языке"*

2011-2013 елларда башлангыч белем бирү баскычының I-III сыйныфлары өчен «Татар теле» һәм «Әдәби уку» фәннәре буенча дәреслекләр әзерләнде: рус телле балаларга өч комплект, татар мәктәпләре өчен – биш һәм рус мәктәбендәге татар балалары өчен дүрт комплект булдырылды. Рус телле II-IV сыйныф укучылары өчен хрестоматияләр төзелде, алар сыйныфтан тыш уку өчен яки дәресләрдә өстәмә материал буларак файдаланыла ала. Укытучы хрестоматиядә тәкъдим ителгән әсәрләрне куллану мәсьәләсен үзе хәл итә.

Рус телле укучылар төркемнәрендә "Татар теле" һәм "Әдәби уку" фәннәреннән бер үрнәк программа, дәреслекләр интегратив характерда төзелгәннәр. Шуның белән беррәттән, яңа буын белем бирү стандартлары һәм базис уку-укыту планнары нигезендә, укытучыларның эш программаларында һәр фәннән планлаштырыла торган нәтиҗәләр аерым күрсәтелергә тиеш.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан I-XI сыйныфлар өчен «Татар теле», «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәре буенча, федераль дәүләт белем стандартларына нигезләнеп, өч юнәлештәге (татар телендә төп һәм урта гомуми белем бирүче мәктәпләр, рус телендә төп һәм урта гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәре һәм рус телендә сөйләшүче балалар төркемнәре өчен) үрнәк программалар әзерләнде. Үрнәк программалар Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына урнаштырылды*:* ***mon.tatarstan.ru/,*** *национальное образование,/ программы по татарскому языку и литературе/.*

Яңа программалар буенча укыту федераль дәүләт белем стандартларына күчү белән турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа карамастан, авторлык программалары, яңа дәреслекләр язылып беткәнне көтмичә, үрнәк программалар 2013/2014 нче уку елында мәктәпләрдә кулланыла. Гамәлдә булган дәреслекләрдәге материалны укытучы шулай ук үрнәк программаларга нигезләнеп куллана. Үрнәк программаларга кертелгән материал һәм әсәрләр өйрәнелергә мәҗбүри, а калган материалны укытучы, сыйныфтагы укучыларның психологик һәм физиологик үзенчәлекләреннән чыгып, иҗади файдалана. Укучыларның белемнәрен тикшерү өчен материаллар әлеге үрнәк программаларда күрсәтелгән планлаштырыла торган нәтиҗәләргә таянып төзеләчәк.

Шулай итеп, V-IX һәм X-XI сыйныфлар өчен үзләренең эш программаларын укытучылар, үрнәк программаларга, гамәлдәге авторлык программаларына һәм дәреслекләргә таянып, төбәкнең ихтыяҗларын, мәктәпнең белем бирү программасы үзенчәлекләрен һәм балаларның әзерлек дәрәҗәсен, шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзиләр. Мәҗбүри шарт: үрнәк программалардагы материал һәм әсәрләр һәр укытучының эш программасында сакланырга тиеш. Уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешендә, материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә һәм эчтәлекне киңәйтүдә укытучылар тарафыннан үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

Федераль дәүләт белем стандартларында урнаштырылган таләпләр гомуми белем бирүнең барлык баскычларында укытуның яңа ысулларын, эффектив укыту технологияләрен куллануны таләп итә. Рус төркемнәрендә татар теле һәм әдәбияты укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан белем бирү процессы коммуникатив технологияләргә нигезләнеп оештырылырга тиеш. Сыйныф журналларында «Татар теле», «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәре аерым языла, рус төркемнәрендә әлеге дәресләр үзара бәйләнештә, интегратив нигездә укытыла.

Министрның беренче урынбасары Д.М. Мостафин

Ә.Р.Морозова
292-49-24

Лист согласования к документу № 12138/13 от 07.09.2013
Инициатор согласования: Морозова А.Р. Начальник сектора учебно-методического сопровождения образовательного процесса
Согласование инициировано: 06.09.2013 20:06

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мустафин Д.М. | - | Подписано 07.09.2013 09:50 | - |